СОВЕТ
НАБЕРЕЖНО-МОРКВАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯР БУЕ МОРКВАШЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

Ул. Красавина, д.40, с. Набережные Моркваши, 422594

Красавин ур., 40 нче йорт, Яр Буе Моркваши авылы, 422594

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

РЕШЕНИЕ КАРАР

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

08.11.2024 с. Набережные Моркваши 53-305

Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Моркваш авыл җирлегенең
Покровка торак пункты территориясенең бер өлешендә үзара салым кертү һәм
аннан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Яр буе Моркваш авыл җирлеге Уставының 24 статьясына туры китереп,

Югары Ослан муниципаль районы
Яр буе Моркваш авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. 2024 елның 23 ноябренә Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Моркваш авыл җирлеге Покровка торак пункты территориясендә гражданнарның үзара салым акчасын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Моркваш авыл җирлегенең Покровка торак пункты территориясенең бер өлешендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда үзара салымны 2000 сум күләмендә кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә сез риза булырсызмы:

- Покровка торак пунктының Үзәк урамы чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча: Покровка авылы, Үзәк урамда 28 нче йорт янында 12.00 сәгатьтә үткәрергә.

4. Яр буе Моркваш авыл җирлегенең Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет рәисе,
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Яр буе Моркваш авыл җирлеге башлыгы И.Х. Гаязов